*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл** ________ __________________ **Шифр** _____________
*(подпись председателя жюри)*

**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**заключительный этап**
**2023-2024 учебный год**
**9 класс**

**I. Хәзерге вакытта татарча сөйләмдә кулланыла торган 5 яңа алынма сүзгә мисал китерегез, мәгънәсен аңлатыгыз.** / Приведите 5 новых заимствований, используемых в современной татарской речи, объясните их значения. *(10 баллов. За каждый пример по 2 балла).*

Җавап: Мәсәлән, фейк – дөрес булмаган мәгълүмат;

Стартап – алга таба финанслау таләп итә торган коммерция проекты.

Логотип – график рәсем, эмблема яки символ;

Лизинг – финанс хезмәтенең бер төре, кредит хезмә күрсәтү формасы;

Бренд – 1 компания товары яки хезмәтен башкаларныкыннан аеру өчен кулланыла торган символ, билге Һ.б.

**II. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" нә теркәлгән мәгънәләреннән чыгып, сүзне табыгыз. /** Отгадайте слова по заначению, зафиксированному в "Толком словаре татарского языка". *(10 баллов. Каждое слова оценивается 2 баллами).*

**КАНИКУЛ** - *лат.* 1) Мәктәптә, уку йортында укучыларның тукталып тору вакыты; 2) Парламент эшендә тукталып ору вакыты

**КИЧ** – көннең кояш баю алдыннан һәм кояш баегач шәфәкъ сүнгәнче булган дәвере.

**МИШӘР** – татар теленең көнбатыш диалектындасөйләшә торган этник төркем вәкиле.

**САРЫК** – 1) куышмөгезлеләр семьялыгыннан куе йон белән капланган имезүче вак йорт хайваны; 2) *күч. гади. сөйл*. булдыксыз, бик юаш, надан һ.б.ш. кеше.

**ТӘҮГЕ** - иң баштагы , беренче ; башлангыч.

**III. Төшеп калган сүзләрне, кирәкле формага куеп, текстта өстәп языгыз. /** Запишите пропущенные слова, поставив в нужной форме. (10 баллов. За каждый правильный ответ по 1 баллу).

**Игътибар** сүзе өч 1) иҗектән __________________ тора. Сүздә 2) сигез ________ хәреф, җиде аваз бар. Сузык авазлар: [и] һәм [а], тартыклар 3) [х], [т] ,[б], [р] авазлары Сүз сингармонизм законының рәт гармониясенә 4) буйсынмаган_______________ . Сүзнең әйтелеше белән язылышы арасында аерма 5) бар ___________ . Игътибар сүзенә 6) калын______________ кушымча ялгана, чөнки 7) соңгы иҗек калын ______. Бу сүз - 8) гарәп _________ алынмасы. Ул 9) фикерләү, күрү һәм ишетү сәләтенең берән нәрсәгә төбәлгән булуы, дикъкать; 1) ихтирамлы мөнәсәбәт, хөрмәт, илтифат, ихтирам _______________________________________________________________ дигәнне аңлата. Бу сүздән 10) _игътибарлы, игътибарсыз_________________ сыйфатлары ясала.

**IV. Бирелгән сүзләр һәм аларда очрый торган грамматик категорияләр арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз.** / Установите соответствия между словами и их грамматическими категориями *(10 баллов. Каждое правильное соответствие оценивается по 2 баллу.)*

| | |
|---|---|
| 1. Дәрестә | А) дәрәҗә |
| 2. Улым | Ә) заман |
| 3. Зәп-зәңгәр | Б) килеш |
| 4. Укучы (малай) | В) юнәлеш |
| 5. Белеш | Г) тартым |

**Җавап: 1 Б 2 Г 3 А 4 Ә 5 В**

**V. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез** / Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения (15 баллов. За каждое задание по 5 баллов).

*Алда утырган абый Илсөяргә болай диде: “ Хәзер син, акыллым, минем кайбер сорауларыма җавап бир” . ( Г.Х.)*

Беренче җөмлә - алда утырган абый Илсөяргә болай диде. Ияse – абый, хәбәре – диде; алда утырган – аергыч, Илсөяргә – тәмамлык, болай – тәмамлык.( ул - ике җөмлә арасында бәйләүче чара).

Икенче җөмлә - Хәзер син, акыллым, минем кайбер сорауларыма җавап бир. Иясе – си, хәбәре – җавап бирерсең. Хәзер – вакыт хәле, акыллым – эндәш сүз, минем – аергыч, кайбер - - аергыч, сорауларыма – тәмамлык.

Бу –иярченле кушма җөмлә. Беренче җөмлә – баш җөмлә, икенче җөмлә - аналитик иярчен тәмамлык җөмлә. Бәйләүче чара – мөнәсәбәтле сүз һәм көттерү паузасы.

1) [ ] : 2) ( .. .) .

**VI. Хәзерге татар әдәби телендә теге яки бу эшне, гамәлне, процессны башкару кирәклеге, тиешлеге ничек белдерелә? Шул грамматик формалар турында языгыз. Мисаллар белән аңлатыгыз.** / Как передается модальное значение необходимости процесса, действия в современном татарском литературном языке? Напишите об этом. Приведите примеры. (15 баллов. За описание и подтверждение примером каждой формы по 5 баллов).

Татар телендә кирәклек, тиешлек модальлеге эшнең булу – булмавы мөмкинлеген яки мөмкин түгеллеген аңлата. Ул түбәндәге грамматик формалар белән белдерелә ала :

1) Инфинитив формасы һәм тиеш модаль сүзе ярдәмендә: Мин дәрескә барырга тиеш.
2) Инфинитив формасы һәм кирәк модаль сүзе аша: Миңа мәктәпкә барырга кирәк.
3) –асы бар, -асы юк - сыйфат фигыль һәм бар/юк сүзләре ярдәмендә. Минем дәрескә барасым бар.
4) –асы бул - сыйфат фигыль һәм ярдәмче фигыль формасы аша: Иртәгә иртә барасы була.
5) –асы кал - сыйфат фигыль һәм ярдәмче фигыль формасы аша: Моны үзенә әйтәсе кала.

**VII. Сүзтезмәдәге һәр сүзне антонимы белән алыштырып языгыз/** Запишите словосочетания, заменив каждое слово антонимом. *(10 баллов.* За каждый правильный ответ по 2 балла*.)*.

Хәзер искә төшү – аннары оныту
Кичен йоклау – иртән уяну
Еракка кычкыру – якында пышылдау
Озакка китү – азга килү
Кышын шаяру – җәен моңсулану (күңелсезләнү)

**VIII. «Гадилектә -бөеклек» дигән сүзләрне сез ничек адлыйсыз? Бу фикергә үз мөнәсәбәтегезне 70 сүздән ким булмаган язмада белдерегез. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез. / Как вы понимаете выраңение** “Величие в простоте”? Напишите сочинение-рассуждение (не менее 70 слов), выражая ваше отношение к этому. Приведите не менее 2 довода-примера. *(20 баллов)*

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге гомуми. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил дә юк | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки** | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | язмада төрле грамматик формалар кулланылган, **ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |